Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Яңа Иштирәк авыл җирлеге
Яңа Иштирәк авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлар, сугыш һәм хәрби хәрәкәт ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар һәм ялгыз пенсионерлардан тыш, аларның саны җирлектә яшәүче халыкның 30 процентыннан артмаска тиеш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
-Яңа Иштирәк авылында су линиясе һәм янгын гидрантлары төзү;
җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:
- Яңа Иштирәк авылының Садовая урамы буенча иске агачларны кисү

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 452 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 229 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлегенең Яңа Иштирәк авылында гражданнар җыены карар бирде:
1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлеге составына керүче Яңа Иштирәк авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Яңа Иштирәк авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, беренче төркем инвалидлар, сугыш һәм хәрби хәрәкәт ветераннары, көндезге формада белем алучы студентлар һәм ялгыз

пенсионерлардан тыш, аларның саны җирлектә яшәүче халыкның 30 процентыннан артмаска тиеш, 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

җирлек торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

-Яңа Иштирәк авылында су линиясе һәм янгын гидрантлары төзү;

җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, әлеге кагыйдәләргә туры китереп, җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Яңа Иштирәк авылының Садовая урамы буенча иске агачларны кисү соравы буенча карарны кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Яңа Иштирәк авылы, Үзәк урам, 7 йорт адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Яңа Иштирәк авыл җирлеге башлыгы Г.Р.Мәүлетова